ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.10.2024 ел Баулы шәһәре №135

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 15 мартындагы 67 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы бюджетына административ комиссия тарафыннан салынган административ штрафларны түләү буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану һәм исәптән чыгару турында карарлар кабул итү тәртибенә (2020 елның 24 апрелендәге 88 номерлы, 2020 елның 20 июлендәге 147 номерлы, 2024 елның 28 августындагы 118 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 6 маендагы 393 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында" 2024 елның 10 октябрендәге 1360 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 15.03.2019 елның 15 мартындагы 67 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы бюджетына административ комиссия тарафыннан салынган административ штрафларны түләү буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану һәм исәптән чыгару турында карарлар кабул итү тәртибенә (2020 елның 24 апрелендәге 88 номерлы, 2020 елның 20 июлендәге 147 номерлы, 2024 елның 28 августындагы 118 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

3 нче бүлектә:

в пунктчасында "хисаплыктан өземтә” сүзләрен “белешмә” сүзенә алмаштырырга ;

г) пунктчасында “Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.1 статьясы нигезендә бюджетка түләүләр, алар буенча пенялар һәм штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтү буенча бюджет керемнәре администраторы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру регламентында каралган” сүзләрен өстәргә.”;

д) пунктчасында:

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «амнистия турында акт яисә штраф рәвешендә җәзага хөкем ителгәннәргә карата ярлыкау акты яисә бюджет керемнәре администраторы бюджетка түләүләр буенча бурычны, шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән срогы тәмамлануга бәйле рәвештә, түләтү мөмкинлеген югалта торган суд акты;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"гражданның судтан тыш банкротлыгы процедурасын тәмамлау турында банкротлык турында белешмәләрнең Бердәм федераль реестрыннан белешмәләр булган документ.”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров